ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

06.10.2023 с. Большие Меми № 1

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 31 октябрендә 9.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 31 октябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 31 октябрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Олы Меми авылы, Заречная урамы, Исаевка урамында яшәүчеләр
2 этап: Олы Меми авылы, Яшьләр урамында яшәүчеләр
3 этап: Олы Меми авылы, Гаврилов Я.А.урамы, Үзәк урамында яшәүчеләр

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Товарны тәэмин итүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр китерү белән, Олы Меми авылы юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Гражданнар җыеннарын уздырырга:

1 этап: Олы Меми авылы, Заречная урамы буенча 15 нче йорт янында
2 этап: Олы Меми авылы, Яшьләр урамы буенча 18 нче йорт янында
3 этап: Олы Меми авылы, Гаврилов Я.А. урамы буенча 45 нче йорт янында

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина